**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

«20» апреля 2020 с. Тюлячи № 183

Эшсез һәм мәшгуль булмаган гражданнар, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар, 2020 елның чыгарылыш сыйныф укучылары өчен иҗтимагый һәм вакытлы эшләр оештыру турында

ДКУ «Теләче районының мәшгульлек үзәге» 2020 елның 17 апрелендәге 32 номерлы хатын карап, Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Законы (2016 елның 28 декабрендәге 425-ФЗ номерлы редакция) нигезендә, эшсез һәм мәшгуль булмаган гражданнарны 2020 елда Теләче муниципаль районында җәмәгать һәм вакытлыча эшләргә җәлеп итү максатларында, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре җитәкчеләренә оештыруны тәкъдим итәргә:

- эшсез һәм мәшгуль булмаган гражданнар өчен җәмәгать эшләре, 1 номерлы кушымта нигезендә;
- социаль яклауга аеруча мохтаҗ эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру, 2 номерлы кушымта нигезендә;
- беренче тапкыр эш эзләүче башлангыч һәм урта һөнәри белем алучылар арасыннан 18-20 яшьлек эшсез гражданнаны вакытлыча эшкә урнаштыру, 3 номерлы кушымта нигезендә;
- беренче тапкыр эш эзләүче гомуми белем бирү учреждениеләрен һәм югары һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар арасыннан эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру, 3 номерлы кушымта нигезендә;
- вакытлыча һәм җәмәгать эшләренә җәлеп ителгән эшсез гражданнарның хезмәтенә федераль законнарда билгеләнгән минималь хезмәт хакы (бердәм социаль салымны да кертеп) күләмендә түләү.

2. Әлеге карарны үтәгәндә, район учреждениеләре, оешмалары һәм предприятиеләре җитәкчеләренә мәшгульлек хезмәте һәм эш бирүчеләр хисабына халыкның мәшгульлегенә булышлык итү һәм эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чараларын финанслау тәртибе турындагы нигезләмәдә каралган суммалар чикләрендә гражданнарның мәшгульлеген

оештыру турындагы Нигезләмәгә таянып эш итәргә тәкъдим итәргә (РФ Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2006 елның 4 сентябрендәге 624 номерлы Боерыгы).

3. «Теләче районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә эш бирүчеләр белән карарның 1 пунктында күрсәтелгән категория гражданнарны эш белән тәэмин итүне оештыру турында килешүләр төзергә тәкъдим итәргә.

4. Предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- эш вакыты нормалары кысаларында эшсез, мәшгуль булмаган гражданнар өчен вакытлыча эш белән тәэмин итүне оештырырга;

- гражданнар тарафыннан эшкә җибәрелә торган сроклы хезмәт килешүләрен төзүне һәм хезмәтне саклау һәм җитештерүдә куркынычсызлык техникасы буенча норматив актларны үтәүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең урынбасары – территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге буенча бүлек начальнигы И.Ә. Миңнегуловка йөкләргә.

Җитәкче Н.Н. Хаҗипов

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«20» 04 2020 № 183
карарына 1 номерлы
кушымта

2020 елда җәмәгать эшләрен оештыру һәм үткәрү буенча "Теләче районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" дәүләт казна учреждениесе белән берлектә район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре тарафыннан оештырыла торган эш урыннары һәм анда катнашучылар санын исәпләү

| Предприятие, оешмалар,учреждениеләр | Булдырыла торган эш урыннары саны | Катнашучылар саны |
|---|---|---|
| Үзәк авыл җирлеге башкарма комитеты | 6 | 6 |
| Әбде авыл җирлеге башкарма комитеты | 6 | 6 |
| ШП Зиннәтуллин Р. А. | 6 | 6 |
| «Ошма» СХСиСПК | 3 | 3 |
| «Мишә» ҖЧҖ | 19 | 19 |
| **БАРЛЫГЫ:** | **40** | **40** |

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«20» 04 2020 № 183
карарына 2 номерлы
кушымта

2020 елда «Теләче районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе белән берлектә предприятиеләр, оешмалар, район учреждениеләре эшчәнлеге барышында төзелә торган катнашучылар һәм эш урыннары санын исәпләү

| Предприятие, оешмалар, учреждениеләр | Булдырыла торган эш урыннары саны | Катнашучылар саны |
|---|---|---|
| Әбде авыл җирлеге башкарма комитеты | 1 | 1 |
| Айдар авыл җирлеге башкарма комитеты | 1 | 1 |
| Олы Мәтәскә авыл җирлеге башкарма комитеты | 1 | 1 |
| Олы Нырсы авыл башкарма комитеты | 1 | 1 |
| «Теләче Агро» ҖЧҖ | 2 | 2 |
| **БАРЛЫГЫ:** | **6** | **6** |

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«20» 04 2020 № 183
карарына 3 номерлы
кушымта

Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре тарафыннан «Теләче районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе белән берлектә 2020 елда беренче тапкыр эш эзләүче гомуми белем бирү учреждениеләрен, урта һәм югары һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар арасыннан эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру буенча эш урыннары санын исәпләү

| Предприятие, оешмалар, учреждениеләр | Булдырыла торган эш урыннары саны |
|---|---|
| «ЛМР Пласт» ҖЧҖ | 1 |
| «Авангард-строй» ҖЧҖ | 2 |
| **БАРЛЫГЫ:** | **3** |